**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы**
**Калмия авыл җирлеге составына керүче**
**Малтабар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

25 октябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Советы 30.10.2019 ел, № 9/2 «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында" нигезләмәне раслау хакында» карары белән 2024 елның 25 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (Биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (Ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Хәрби Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (Малтабар авылының зиратын төзекләндерү, зиратка койма сатып алу һәм урнаштыру).

“ӘЙЕ” “ЮК”.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 123 кеше катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 66 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 66 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы территориясендә яшәү

урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (Биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (Ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Хәрби Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (Малтабар авылының зиратын төзекләндерү, зиратка койма сатып алу һәм урнаштыру)» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмия авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Закиров